ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
КШКЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

# КАРАР

31 октябрь 2025 ел № 4

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2025 елның 14 нче ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының үткәрү вакыты – 14 ноябрь 2025 ел 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны – Кызыл Утар авылы, Ленин урамы, 4 нче йорт, Кызыл Утар авыл клубы залы;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 5 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Яңа Өҗем торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Яңа Өҗем торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан,

беренче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Яңа Өҗем авылы территориясен чистарту (үлән чабу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); бензин триммеры сатып алу.

2) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру), эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).”

“РИЗА” “КАРШЫ”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталыда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Кызыл Утар авылы, Ленин урамы 4 нче йорт адресы буенча авыл клубы бинасындагы стендка урнаштырырга.
3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы: А.Х.Кашшапов